ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

АКБАШ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ
423958 Ютазы районы,
Акбаш авылы, Мәктәп урамы, 1
тел. 4-14-34
факс: 8 (85593) 4-14-34

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
АКБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
423958 Ютазинский район
село Акбаш ул.Школьная, д.1
тел. 4-14-34
факс: 8 (85593) 4-14-34

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

N 1 31 .10.2022

2023 елда «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнарга үзара салым (бер мәртәбә түләүләр) акчаларын кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 20, 35 маддәләре, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 июлендәге 10 санлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 14, 81 маддәләре, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Советының 2019 елның 23 сентябрендәге 15 санлылы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Акбаш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында»гы нигезләмә нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районының Акбаш авыл җирлеге, Акбаш авылы, Мәктәп урамы, 17 йорт адресы буенча урнашкан КФҮ бинасы янында 2022 елның 12 ноябренә 18 сәгатькә билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Акбаш авылы җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм аларга тиңләштерелгән затлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге

мәсьәләләрне хәл итүгә алынган юлламалардан тыш, 2023 елда үзара салым (бер тапкыр түләнә торган түләүләр) кертүгә сез килешәсезме:

- Акбаш торак пунктында янгын гидрантларын сатып алу, урнаштыру (килешү буенча эшләрне түләү).
- Акбаш т. п. Тукай урамы буенча юлны асфальтлау;
- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге территориясендә җирлек эчендәге юлларны карап тоту (юлларны кардан чистарту, шартнамә буенча эшләр өчен түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Акбаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталы составында "Рәсми Татарстан" дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм порталы составында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгән көннән үз көченә керә.

"Акбаш авыл җирлеге"
муниципаль берәмлеге башлыгы Л.Р.Синәгатуллина